**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«27» март 2017 ел № 13/7

**Муниципаль милекне Татарстан Республикасы милкенә тапшыру турында**

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы Тукай һәм Түбән Кама муниципаль районнарына эш сәфәре йомгаклары буенча йөкләмәләре исемлегенең 7 пунктын үтәү йөзеннән (№ ПР-51, 2016 елның 2 мартында), «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль милкен кушымта нигезендә Татарстан Республикасы милкенә тапшырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тоту законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев